# Инсафлының теле саф

Презентация авторы:

Заһидуллина Рәйсә Кадыйр кызы
Казан шәһәре 170 нче мәктәп



Эзләнү эшнең темасы “**Инсафлының теле саф**”.

Башта “инсафлы” сүзенә аңлатма биреп үтик :

**Инсафлы** – **1**. сф.Әдәпле, тыйнак, тәүфыйклы, бик инсафлы кыз.

**2**. рәв.мәгън. Әдәпле , тыйнак, тәүфыйклы. Үзен инсафлы тоту. Инсафлы гына йөрү.

**Эзләнү эшнең төп максаты :**

Тел – бөек хәзинә икәнлеген,
мисаллар ярдәмендә телебезнең чуарлана баруын исбатлау.

**Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны билгеләдек:**

- Туган телебезнең сафлыгын, матурлыгын, дөнья телләре арасында тоткан урынын ачыклау.
- Инсафлының теле саф, йөзе күркәм, күңеле чиста булуын җиткерү;
- Телебезне саф килеш саклап кала алу мөмкинлекләрен билгеләү.

 

**Эзләнү эшнең актуальлеге:**

Безнең әби-бабаларыбыз тел һәм әдәбиятны белмәсәләр дә, бала сөйләмендә чит- ят сүзләр буталганын яратмаганнар , татарның татар белән саф татарча сөйләшүен таләп иткәннәр.



Зиннур ХӨСНИЯР

# Тәмле сүзләр

Мин яраткан иң татлы сүз:
— Ул — *мәми.*
Мәмидән дә тәмлерәк сүз:
— Ул — *әни.*
Әни белән әти өчен:
— Мин — *бәби.*
Ә бәбигә иң баллы сүз:
— *Әти-әни...*

Сизәсеңме, ошбу тәмле сүзләрне әйтүгә синең авыз эчең баллана башлады. Ә баллы авыздан әти-әнигә карата бары тик татлы җөмләләр генә чыга:
— *Рәхмәт! Бик зур рәхмәт! Ходай кабул итсен!*
— *Исән-саумы? Ни хәлләрең бар?*
— *Сау-сәламәт бул! Алланың рәхмәте яусын! Мин сине бик яратам!*

Тәмле сүзләр белән иң нәни чактан ук иркәләп сөюче, дөньядагы иң сөйкемле зат — әниебезгә Ходай рәхмәте яусын... Амин! Шулай булсын!

ӘТИ – папа – dad, daddy ['дэдь, дэддьи]
ТӘМЛЕ – вкусный – delicious [дэли'шэс]
БАЛЛЫ – сладкий – sweet ['суить]
РӘХМӘТ – спасибо – thank you, thanks ['фэнк ю, фэнкс]
НӘНИ – маленький – little one ['литтл уан]
ХОДАЙ – бог – god ['гадь]

Рәссам Алла АЙСЕНА

7

Безнең сөйләмебез аерым сүзләрдән, әйтелмәләрдән һәм җөмләләрдән тора. Сүзләр һәм сүзтезмәләр җөмлә эчендә, үзара бәйләнешкә кереп, билгеле бер фикер белдерәләр.

**Сүз** – күпьяклы һәм катлаулы тел берәмлеге. Сүзгә дистәләрчә билгеләмәләр бирелсә дә, төп үзлекләре ачыкланса да, сүз әле бүген дә ачылмаган очсыз-кырыйсыз сер дингезе булып кала бирә.

# Сөйләмдә кирәксез сүзләр.

Кайчак әдәби телдә дә, халык телендә дә сөйләмнең табигый агышына комачаулый һәм бернинди дә мәгънә белдерми торган “артык” сүзләр дә очрый.

Күп таралган “артык” сүзләрнең берсе – “булган”сүзе. Мәсәлән: 1.“Әһәмиятле булган мәсьәләләр турында фикер алышачаклар.”/радио/.2. “Кубада иң зур булган текстиль комбинаты төзелеп килә.”/радио/.

# Тел турында мәкаль - әйтемнәр.



Әйт кенә тәмле сүз –
Иркәләр күпме күз.
Әйт кенә яхшы сүз –
Һәркемдә көләч йөз.

Халык югары тел культурасына ия булуны элек –электән үк кешенең иң күркәм әхълак сыйфатларының берсе итеп санаган. Фольклор әсәрләрдә: мәкаль - әйтемнәрдә , әкият , гыйбрәтле хикәя ,мәзәкләрдә тел , сүз кешене бәяләүнең иң төп үлчәме булып торган. Мәсәлән:

- Кешенең акылы сүзеннән , асылы эшеннән беленә.
- Инсафлының теле саф.
- Теле бозыкның күңеле бозык.
- Акылы кысканың теле озын.
- Теле яман теле белән тере агачны корытыр.



Без кешеләр арасында яшибез , бер көн эчендә генә дә  күпме кеше белән очрашабыз , аралашабыз. Иң беренче чиратта без, әлбәттә , кешенең тышкы кыяфәтенә игътибар итәбез, йөзенә карыйбыз, ничек киенүен тикшерәбез. Аннан соң инде якынырак танышабыз , сөйләшәбез , аралашабыз.

# Тел турында галимнәрнең фикерләре:

“Вакытында әйтелгән сүз генә асыл.
Алдан әйтелсә – көлке,
Соңга калса – төссез”.

**Факил Сафин.**

“Кыска акылның теле озын “.

**Аристофан.**

“Сүзне колак белән ишетәләр,
Йөрәк белән үлчиләр”.

**Мөҗәһит Әхмәтҗанов.**

“ Яратыгыз сүзне. Сокланыгыз аңа. Саклагыз. Җыегыз аны. Алмаз, чәчкә җыйган кебек. Җыегыз. Эзләгез. Табыгыз. Кулланыгыз. Сүз сөйләгәндә, йолдыз чәчегез. Тыңлаучының йөзе яктырсын. Күңелендә энҗе - мәрҗәндәй уйлар, әгъла хисләр тусын”.

**Йосыф Гәрәй.**

# Матур сөйләшә беләбезме? (анкета нәтиҗәләре).

мин татарча сөйләшәм!



**Йомгаклау:**

Тикшерүләрдән чыгып, мин шундый нәтиҗә ясап була:

туган тел –ул безнең балачагыбыз,гаиләбез,җәмгыятьтәге беренче аралашу телебез.Шуңа да саклыйк,хөрмәт итик, чит сүзләр белән буямыйк аны. Беркайчан да  телне онытмассыз, пычратмассыз , ягымлы , шифалы сүзләр генә әйтерсез дип ышанып каласым килә. Шулай булганда гына безнең культурабыз үсәр, кешеләр белән аралашу зур бәхет булыр.

**Файдаланылган әдәбият.**




1. Дөрес сөйләргә өйрәнегез. А.Х.Хәйруллина. Казан : “Казан “ нәшрияты, 1992.96 б.
2. Җылы сүз җан эретә. Р.А. Юсупов. Казан, 1996.
3. И туган тел...И.М.Низамов. Казан 1998.
4. Инсафлының теле саф / Дөрес сөйләм турында иншалар/ Р.А.Юсупов. КДПИ, Казан, 1993,165 б.
5. Интернет сайты .http://www.iset.edusite.ru/p47aa1.html
6. “Мәгариф”журналы. 1982 №11,12;1998 №3.
7. Мәктәптә тел культурасы. Г.Ф. Саттаров.Казан ,1965.
8. Татар теле дәреслеге. 8нче сыйныф өчен дәреслек /Ф.С.Сафиуллина, Р. Х. Мөхиярова, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2008.
9. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге , Казан, “Матбугат йорты” нәшрияты, 2005,187 б.
10. Укучыларда сөйләм культурасын тәрбияләү.Р.А. Юсупов.Казан,1983.

# Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

